Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы

2024 елның 27 ноябре № 51/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә туристлык салымын билгеләү һәм гамәлгә кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 33.1 бүлеге, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында» 1996 елның 24 ноябрендәге 132-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә туристлык салымын билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын салым базасыннан киләсе күләмдә билгеләргә:
1) 2025 елда - 1 процент;
2) 2026 елда - 2 процент;
3) 2027 елда - 3 процент;
4) 2028 елда - 4 процент;
5) 2029 елдан башлап – 5 процент.

3. Салым түләү тәртибен Россия Федерациясе Салым кодексының 418.8 статьясы нигезендә билгеләргә.

4. Вакытлыча яшәү буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясе салым базасына кертелми торган физик затлар категорияләре Россия Федерациясе Салым кодексының 418.4 статьясының 2 пункты белән билгеләнгән.

5. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә туристлык салымын исәпләү тәртибе Россия Федерациясе Салым кодексының 418.7 статьясы нигезендә билгеләнә.

Россия Федерациясе Салым кодексының 418.7 статьясы нигезендә исәпләнгән туристлык салымы суммасы 100 сумның тапкырлавы һәм яшәү тәүлеге саны буларак исәпләнгән минималь туристлык салымы суммасыннан кимрәк булган очракта, туристлык салымы суммасы минималь туристлык салымы күләмендә билгеләнә.

6. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм (яисә) «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

Татар Ялтаны авыл җирлеге
башлыгы Р.Р. Гарифуллин